ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2016 елның 21 июнендәге 1296-V ДС, 2016 елның 15 декабрендәге 1545-V ДС номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктта «бүлекләрдән» сүзеннән соң «, сектордан» сүзен өстәргә;

2) 10 пунктта:

а) беренче абзацта «мөстәкыйль бүлекләр мөдирләре,» сүзләреннән соң «сектор мөдире,» сүзләрен өстәргә;

б) икенче абзацта «Секторлар мөдирләре» сүзләре алдыннан «Идарәләр составындагы» сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $19^1$ пункт өстәргә:

«$19^1$. Аппаратның Яшеренлек режимын тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы секторы Дәүләт Советының гражданнар оборонасы һәм мобилизацион әзерлек чараларын оештыру ягыннан тәэмин итүне һәм үткәрүне гамәлгә ашыра, яшеренлек режимы, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне һәм Дәүләт Советы биналарының янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы затларның эшчәнлеген тикшереп торуны тәэмин итә, шулай ук Дәүләт Советы Аппаратының Административ регламентына һәм Аппаратның

Яшеренлек режимын тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы секторы турындагы нигезләмәгә таянып башка функцияләрне башкара.».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 16 октябре
№ 98-VI ДС